РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр
пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 84

2021 елның 01 декабре

# Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 4 пунктын өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«контроль-хисап палатасы рәисе урынбасарына айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме контроль-хисап палатасы рәисенә айлык җыелма акчалата түләү күләменең 0,8 еннән артмаска тиеш;

«контроль-хисап палатасы аудиторына айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме контроль-хисап палатасы рәисенә айлык җыелма акчалата түләү күләменең 0,6 сыннан артмаска тиеш;»;

карарга 1 нче кушымтада:

таблицаның 6 нчы юлында «22 798» цифрлы кыйммәтен «28 286» цифрлы кыйммәтенә алмаштырырга;

таблицаның 7 нче юлында «18 530» цифрлы кыйммәтен «23 686» цифрлы кыйммәтенә алмаштырырга.

2. Түбән Кама муниципаль район Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарына әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль

берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары — А.В.Умников